

## Болыттан туган тал баласы

Бу хәл моннан күп гасырлар элек булды.

Болыт баласы күк йөзе буйлап әти-әнисен эзләде. Күк йөзендә йөзә-йөзә, ул, ниһаять, үз өенә кайтты. Әти-әнисен анда да тапмады.

Бу кайгыдан Болыт баласы үксеп-үксеп елады. Аның күз яшьләре яңгыр булып җиргә коелды.

Күз яшьләре төшкән җирдә тал баласы үсеп чыкты. Ул Тәхаветдин иде.

# Таллар шатлыгы

Бу вакыйгадан соң бик күп еллар үтте.

— Кил монда! — диде көннәрдән бер көнне зифа Тал-Егет нәфис Тал-Кызга.

— Килмим әле! — дип җавап бирде зифа Тал-Кыз. — Килми торыйм әле!..

— Ул чакта үзем килимме соң? — диде Тал-Егет. — Киләм дә куям…

— Килсәң… килерсең инде, — диде Тал-Кыз. — Синең белән ни хәл итәсең…

Зифа Тал-Егет нәфис Тал-Кыз янына килде. Алар күрештеләр.

Араларында җирдән кечкенә нәзек тал калкып чыкты.

Бу нәзек тал да Тәхаветдиннәр нәселеннән, аларның яңадан-яңа буыны иде. Башка нәселдәшләреннән аерылып торсын өчен, ата-анасы аңа «Талхәветдин» дигән исем бирде. Аерма бер генә авазда, ә мәгънәсе гаҗәеп тирән иде! «Тәха» сүзе гарәпчәдән «ашчы», «пешекче» дигәнне аңлатса, «талхә» исә «баллы тамыр», «баллы сагыз», «чәер», ягъни «талның баллы баласы» булып чыга икән. Талның баллы баласы! Ничек кенәләр матур!.. Ул да Тәхаветдиннәр нәселеннән, меңенче буын Талхәветдин икән ләбаса!..

Талларның барысын да «Тәхаветдин» дип йөрттеләр. Шунысын да аңлаттылар: һәр тал баласы үзеннән алда яшәгән җиде бабасының исемен яттан белергә һәм, төнлә уятып сорасалар да, шундук әйтеп бирергә тиеш. Әйтик, Сәлахетдин икән — намуслы; Сәхәбетдин икән — пәйгамбәребез көрәштәше; Бәһаветдин икән — кыйммәтле; Иматдин икән — иман-намазга әйдәүче; Илһаметдин икән — хиссиятле; Гамәлетдин икән — эшлекле; Сәхаветдин икән — юмарт… Һәм башкалар, һәм башкалар. Тал балаларына элек-электән шундый матур һәм тирән мәгънәле исемнәр бирелгән булган.

Әнә яр буендагы бер тал баласы икенче тал баласы янына йөгереп килде:

— Синең исемең-атың кем?

— Тәхаветдин улы Талхәветдин!..

— Ә мин — Тәхаветдин улы Җиһанетдин!..

Аларга калган тал балалары да кушылды:

— Ә менә мин Тәхаветдин улы Сәхаветдин!

— Ә мин Тәхаветдин улы Сәрвәретдин!

— Ә мин Тәхаветдин улы Сәбахетдин! — дип шаулашып сикереште алар. — Без нәселебез белән барыбыз да Тәхаветдиннәр!

— Без бихисап!.. Сәбахетдин!.. Бәшәретдин! — дип өстәде Җиһанетдин. — Иманетдин... Сәббахетдин... Без көчле!..

Аларга бар дөнья — Җирнең алты кыйтгасы — Тәхаветдиннәр белән тулган булып күренде. Тал балалары куанычларын кая куярга белми биилӛр иде.



# Төн һәм көн

Шулай итеп елга буе-сахралардагы тал-тамырларның гомере үткән дә үткән. Тал балаларының меңенче буыны Талхәветдинне кара белән ак, төн белән көн, караңгылык белән яктылыкның алмашына алуы борчыган. Дөресрәге, таң калдырган. Һәм аның бу серне бик тә беләсе килгән. Беркөнне Талхәветдинл Көн-Кояштан:

— Кояш, син нигә бу кадәр якты? — дип сораган.

Кояш аңа бу хакта Төн-Караңгылыктан сорарга кушкан.

Тал баласы бу сорауны Төн-Караңгылыкка да биргән. Төн-Караңгылык исә аны яңадан Көн-Кояшка җибәргән.

Тал баласы шушы ук сорау белән кире Көн-Кояшка әйләнеп кайткан.

— Минем сине Төн-Караңгылыкка, Төн-Караңгылыкның кире миңа, Кояшка җибәрүендә зур мәгънә бар, сабый, — дигән Көн-Кояш. — Көндә өлешчә төн караңгылыгы, төндә өлешчә көн яктылыгы бар. Көн үзен яндырып төн ясый, төн үзен яндырып көн ясый. Көн сине көнгә күрсәтә, төн сине төнгә яшерә. Көн сине эшләтә. Төн сине йоклата. Аларның икесе, аллы-артлы булып, гел бергә йөри һәм, шулай итеп, Аллаһы Тәгаләдән төшкән бу бәрәкәтләрнең кадерен белергә өйрәтә…

Моңа кадәр мондый серле күренешләргә игътибар да итмәгән, аларга бер очраклы чынбарлык итеп кенә карап өйрәнгән тал балалары шул заманнардан алып көннең төнгә, төннең көнгә, яктының караңгыга, караңгының яктыга, акның карага, караның акка — берсенең икенчесенә күчүенең үзләре теләп түли торган ихтирам, мәхәббәт һәм сабырлык салымы икәнлеген аңладылар. Алар эшли дә йоклап ял итә, йоклап ял итә дә эшли, ди. Болары да үзләренә күрә шул мәхәббәт һәм сабырлык салымы була, ди. Тал балалары шул көннән бирле Көн-Кояшның яктылыгыннан, Төн-Караңгылыкның караңгылыгыннан мәгънә һәм ләззәт табып яшиләр икән.

— Бу байлыклар каян килә, әни? — дип сорады Талхәветдин, аптырап. — Аларны кем тудырган? Сине, мине кем тудырган?

— Аллаһы Тәгалә тудырган, — диде әнисе тыныч кына. — Алдыңда, артыңда, уңыңда, сулыңда нәрсәләр күрсәң, шул исәптән мине дә, үзеңне дә Аллаһы Тәгалә бар иткән, улым.



— Аллаһ… кем була соң ул? — дип сораганын сизми дә калды тал баласы.

— «Аллаһ» кына димә, «Аллаһы Тәгалә» дип әйтеп өйрән, улым. Аллаһы Тәгалә — дөньяны, дөньядагы тормышны юктан бар итүче Изге көч… — Әнисенең болай да якты йөзе тагын да илһамланып яктырды. Ул, карашын ерак офыкларга юнәлтеп, улына аңлатырга кереште: — Тал балаларының һәр адымын күзәтеп, бәя бирүче. Ул бирәү һәм бердәнбер. Аның затын белеп булмый. Ул тумый һәм үлми. Күзгә күренми. Яшәрми һәм картаймый. Аның сыйфатларын гына белеп була. Мәңгелек мәрхәмәт, изгелек һәм рәхмәт Иясе ул. Шушы көчне Аллаһы Тәгалә, диләр…

Бар күңеле белән әсәрләнгән малай әнисенең бу сүзләреннән соң тынсыз калды. Шуннан соң Талхәветдин һәр күренешкә игътибарлы, үз бәясен бирә торган бала булып китте.